**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2022 елның 28 марты** **27-РС номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 25 октябрендәге 80-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында " 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1.Җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан башкарылган муниципаль контрольнең төп күрсәткечләрен һәм аның максатчан күрсәткечләрен, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә өстәргә.

2. Лаеш муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларының исемлеген, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә өстәргә..

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү йөкләмәләрен бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма башкаруга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда индикатив күрсәткечләр исемлеген, әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә өстәргә.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Советының
2022 елның 28 мартындагы 27-РС номерлы
карарына 1кушымта

**Җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен һәм аның максатчан күрсәткечләрен, бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр**

1. Төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан күрсәткечләре:

Мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозулар арасыннан юк ителгән хокук бозулар өлеше - 70%.

Контроль орган һәм (яисә) аның вазыйфаи затының контроль чаралар уздырганда гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата нигезле шикаятьләр өлеше - 0%.

Контроль чараларның юкка чыгарылган нәтиҗәләре өлеше - 0%.

Нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланган контроль чаралар өлеше, әмма административ йогынты ясауның тиешле чаралары күрелмәгән - 5%.

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Советының
2022 елның 28 мартындагы 27-РС номерлы
карарына 2кушымта

**Перечень индикаторов риска нарушения обязательных требований, используемые для определения необходимости проведения внеплановых проверок при об осуществлении муниципального контроля за исполнением единой теплоснабжающей организацией обязательств по строительству, реконструкции и (или) модернизации объектов теплоснабжения на территории Лаишевского муниципального района Республики Татарстан**

Өч ай дәвамында бер үк җылылык белән тәэмин итү объектларында булган ике һәм аннан да күбрәк авария.

2. Җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы, шулай ук бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма һәм җылылык энергиясен кулланучы арасында барлыкка килә торган каршылыклар мәсьәләләре буенча кулланучыларның ике һәм аннан күбрәк мөрәҗәгате өч ай рәттән.

3. Җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чаралары исемлегенең бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан башкарылмавы.

4. Җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыруның бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан срокларын бозу.

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Советының
2022 елның 28 мартындагы 27-РС номерлы
карарына Зкушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү йөкләмәләрен бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма башкаруга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда индикатив күрсәткечләр исемлеге**

1) хисап чорында үткәрелгән планлы тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;
2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны;
3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүен ачыклау нигезендә үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны,;
4) хисап чорында үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;
5) хисап чорында үткәрелгән КНМның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;
8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;
9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;
12) хисап чорында тикшерү (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
13) прокуратура органнарына хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында гаризалар саны;
14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;
15) хисап чоры ахырына һәр риск категориясе буенча хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны;
16) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;
17) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;
18) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;
19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;
20) хисап чорында контрольлек итүче затлар тарафыннаналарны карау йомгаклары буенча контроль (күзәтчелек) органы карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгару

турында яисә контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлдә түгел дип тану турында Карар кабул ителгән судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләр саны,;
21) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;
22) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъвалау турында, алар буенча гариза бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында Карар кабул ителгән, дәгъва гаризалары саны,.;
23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән, аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.